| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 Баулы шәһәре № 132

Баулы шәһәр Советының 2018 елның
20 апрелендәге 73 номерлы «Баулы
муниципаль районы «Баулы шәһәре»
муниципаль берәмлегенең бюджет
өлкәсе хезмәткәрләренең, хезмәт хакы
буенча Бердәм тариф челтәре
кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым
оешмалары хезмәткәрләренең, хезмәт
хакы шартлары турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләмен арттыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2018 елның 20 апрелендәге 73 номерлы «Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең, хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең, хезмәт

хакы шартлары турында» карарына   района (Баулы шәһәр Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 90 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 140 номерлы, 2022 елның 22 февралендәге 55 номерлы, 2022 елның 26 октябрендәге 70 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 81 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләме «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә Бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе сәркатибенең вазыйфаи хезмәт хакы күләменә тапкырлап исәпләнә, аларга бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый, ул 13 323 сум тәшкил итә.».

3 пунктның  3 пунктчасында «15 процент» сүзләрен  «37 процент» сүзләре белән алмаштырырга»;

7 пунктның  4 пунктчасында «15 процент» сүзләрен  «37 процент» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы рәсми сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе                                        И.И. Гозәеров